**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «16» августыннан № 404

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү (балалар бакчалары) программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 09 июнендәге 1049/17 номерлы боерыгы нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтүне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Мөрәҗәгать итүче Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта укырга хокуклы булса, мөрәҗәгать итүчегә «ТР Яңа Чишмә муниципаль районы

Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУнә ташламаны раслый торган документларның күчермәләрен тапшырырга кирәк, шул ук вакытта мөрәҗәгать итүченең кулында кала торган документларның оригиналы була.

3.6.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Ташламалы категория балалары баланы бер оешмадан икенчесенә күчергәндә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка закон норматив хокукый актларда билгеләнгән ташламалардан файдалана.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**